ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ УРЫССУ БИСТӘСЕ СОВЕТЫ

КАРАР №_4_

Урыссу штб 25.04.2024 ел

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы шәһәр тибындагы
Урыссу бистәсе Советының 2023 елның 01 мартындагы
3 санлы карары белән расланган
шәһәр тибындагы Урыссу бистәсендә
муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору турында»гы 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 23 июнендәге 50-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советының 2023 елның 1 мартындагы 3 санлы карары белән расланган шәһәр тибындагы Урыссу бистәсендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 18.2. пунктның 10 нчы пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Максатчан укыту турында килешү төзү конкурсында Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән, тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белем алучы һәм укуны тәмамлаганнан соң хезмәт мөнәсәбәтләре барлыкка килүгә китерә торган укучы яки башка килешү буенча йөкләмәләре булмаган гражданнар катнаша ала.

Әлеге конкурста катнашучы граждан муниципаль хезмәткә кергәндә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 18.2 пунктының 34 пунктчасында каралган бөтен срок дәвамында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 2007 елның 2 мартындагы 25 - ФЗ санлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.»;

1.2. Нигезләмәнең 18 маддәсендәге 18.1 пунктының 11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»;

1.3. Нигезләмәнең 9 маддәсенең 9.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.4. Муниципаль хезмәткә кергәндә бирелгән мәгълүматлар (анкетада булган мәгълүматлардан тыш) законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерелергә мөмкин. Аерым муниципаль берәмлекләрдә федераль законнар белән муниципаль хезмәткә кергәндә граждан тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларны тикшерүгә өстәмә таләпләр билгеләнергә мөмкин.»;

1.4. Нигезләмәнең 9 маддәсенең 9.3. пунктының 2 пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль законның 15.2 маддәсендә каралган анкета;

1.5. Нигезләмәнең 6 маддәсенең 6.1. пунктының 8 пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән вакытта ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы, яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында документлар һәм (яисә) мәгълүматлар бирмәүче ялган мәгълүматлар тапшыру;»;

1.6. Нигезләмәнең 5 маддәсенең 5.5. пунктын түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктчасы белән тулыландырырга:

«2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль законның 15.2 маддәсендә каралган анкетадагы мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, эш бирүче вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба анкетада булган мәгълүматлар).».

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет»

мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының
шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе
Башлыгы А.Ә. Шәфигуллин